КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 3 февраль г.Казань № 59

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында азсыешлы судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2007 ел, 15 октябрь, 562 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында азсыешлы судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында азсыешлы судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2007 ел, 15 октябрь, 562 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 28 апрель, 258 нче; 2021 ел, 22 июль, 643 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында азсыешлы судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Суднолар йөри торган сулыкларда азсыешлы суднолар йөзү, навигация җайланмасының йөзә торган һәм куелган билгеләре булганда, навигация ачылган вакыттан алып аны япканга кадәр, ә суднолар йөрми торган сулыкларда, ташу сылары бетеп, су өстен боз тотканга кадәр рөхсәт ителә. Азсыешлы суднолар өчен навигация башлану һәм тәмамлану сроклары: 25 апрельдән 1 ноябрьгә кадәр.

Әлеге пункт нигезләмәләре түбәндәгеләргә кагылмый:

дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр тарафыннан үзләренә йөкләнгән контроль (күзәтчелек) функцияләрен һәм һәлакәттән коткару эшләрен гамәлгә ашыру максатларында кулланыла торган азсыешлы судноларга;

су биологик ресурсларын чыгаруга, тотуга рөхсәтләр буенча сәнәгать балыкчылыгын гамәлгә ашыручы, балык үрчетү урыныннан файдалану шартнамәләре буенча балык үрчетүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан кулланыла торган азсыешлы судноларга;

су өстеннән дә, боз өстеннән дә хәрәкәтләнергә сәләтле һава мендәре белән азсыешлы судноларга, махсус конструкциядәге азсыешлы судноларга.»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Һәр азсыешлы судно бәрелешүне кисәтү өчен гамәлләр кылу мөмкинлеге һәм тиешле шартларда һәм хәлләрдә таләп ителә торган ераклыкта туктату мөмкинлеге булган куркынычсыз тизлек белән барырга тиеш.

Азсыешлы суднолар белән портлар, пристаньнәр, азсыешлы суднолар туктап тору өчен базалар (корылмалар), пляжлар һәм су объектларындагы кешеләр күпләп ял итә торган башка урыннар чикләреннән 50 метр зонада хәрәкәт иткәндә, су асты эшләре белән шөгыльләнүче суднолар янында тизлек дулкын китереп чыгармаска һәм иң күбе сәгатенә 10 км тәшкил итәргә тиеш.

Су объектлары акваториясендә азсыешлы суднолар белән күпердән 50 метр зонада хәрәкәт иткәндә һәм аның астыннан үткәндә, тизлек иң күбе сәгатенә 10 км тәшкил итәргә тиеш.

Су объектлары акваториясендә азсыешлы суднолар белән яр буе линиясеннән 50 метр зонада торак пунктлар чикләрендә хәрәкәт иткәндә, тизлек иң күбе сәгатенә 15 км тәшкил итәргә тиеш.

Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәлләре дип игълан ителгән су объектлары акваториясендә азсыешлы суднолар белән хәрәкәт иткәндә, әгәр барлык йөзә торган чараларга (шул исәптән азсыешлы судноларга) йөрергә һәм туктап торырга тыю билгеләнмәсә, тизлек иң күбе сәгатенә 5 км тәшкил итәргә тиеш.

Азсыешлы суднолар белән пляжлар һәм су объектларындагы кешеләр күпләп ял итә торган башка оештырылган урыннар чикләренә кадәр 50 метрдан артык ераклыкта хәрәкәт итәргә рөхсәт ителә.

әлеге Кагыйдәләрнең кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле
дәүләт табигать тыюлыгы акваториясе схемасы

**Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле
дәүләт табигать тыюлыгы» обекты чикләре планы**

**Объект чикләренең күзәтү схемасы**




Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 16 июнь, 324 нче карары нигезендә Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы территориясендә, түбәндәгеләрнең йөзү чараларыннан тыш, барлык йөзә торган чараларга (шул исәптән азсыешлы судноларга) түбәндәгеләрне йөрергә һәм туктап торырга тыю каралган:

махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарның;

тыюлык чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башка дәүләт органнарының һәм муниципаль органнарның;

линия объектларына хезмәт күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру, аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характер йөрткән башка хәлләрне бетерү чараларын үткәрү өчен файдаланыла торган;

«Татарстан көзгеләре» туристлык-рекреация кластеры кысаларында чараларны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин